Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____05.02.2026_____ Менделеевск ш. № __66______

Авыр матди хәлдәге һәм кичектергесез
медицина ярдәменә мохтаҗ гражданнарга
акчалар түләү турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 апрелендәге 190 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын формалаштыру һәм тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә, авыр матди хәлдәге һәм кичектергесез медицина ярдәменә мохтаҗ гражданнарга матди ярдәм түләү кысаларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчалары исәбеннән алына торган гемодиализ буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнарны каплау өчен 2026 елның 1 гыйнварыннан бер кешегә квартал саен 10 000 (ун мең) сум күләмендә лимит билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 30 гыйнварендагы 46 нчы номерлы карарын гамәлгә яраксыз дип санарга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Искаков